ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

11.02.2025 п.г.т.Алексеевское № 43

**2025 елга һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күрсәткечләрен билгеләү турында**

Россия Федерациясе Торак кодексының 49, 50, 51 статьяларына, «Татарстан Республикасы Дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 21.12.2018 ел, № 470 «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы бердәм торак Комиссиясен төзү турында» карарына, «Татарстан Республикасы бәяләүчеләр берлеге» КП ның 27.01.2025 № 26 хатына туры китереп

**карар бирәм:**

1. 2025 елга гражданнарны аз керемле дип тану турында карар кабул итү өчен чик кыйммәтләрен билгеләргә (Кушымта):

1.1. гаилә әгъзалары (ялгыз яшәүче граждан) милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәтнең бәясе чиге:

1.1.1. ялгыз яшәүче граждан өчен – 824 508 сум;

1.1.2. ике кешедән торган гаилә өчен – 1 649 016 сум;

1.1.3. өч кешедән торган гаилә өчен – 2 473 524 сум;

1.1.4. дүрт кешедән торган гаилә өчен – 3 298 032 сум;

1.1.5. биш кешедән торган гаилә өчен – 4 122 540 сум;

1.1.6. алты кешедән торган гаилә өчен – 4 947 048 сум;

1.1.7. җиде кешедән торган гаилә өчен – 5 771 556 сум;

1.2. гаиләнең һәр әгъзасына туры килгән уртача айлык гомуми керем күләме:

1.2.1. ялгыз яшәүче граждан өчен – 38 811 сум;

1.2.2. ике кешедән торган гаилә өчен – 38 811 руб.;

1.2.3. өч һәм аннан да күбрәк кешедән торган гаилә өчен – 38 811 сум;

2. Бердәм торак Комиссиясе әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктларына

таянып, гаиләнең һәр әгъзасының яки ялгыз яшәүче гражданның керемен исәпләгәндә, аларны социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирүгә мохтаҗ дип тану максатында эш итәргә тиеш.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында веб-адрес буенча: http://alekseevskiy.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары Р.С. Язынинга йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **О.Н. Леденцов**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
_11.02.2025_ № _43_
карарына кушымта

**2025 елга һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле молкәт хакының иң чик күрсәткечләрен билгеләүне исәпләп чыгару**

1. СЖ = НП х РС х РПС, монда

СЖ - базар бәясенең исәпләнгән күрсәткече яки милек бәясе чиге;

НП - бер гаилә әгъзасына торак урыны бирү нормасы;

РС - гаилә әгъзалары саны

РПС - Торак урын мәйданының бер квадрат метрының уртача исәпләнгән базар бәясе-45 806 сум. «Татарстан Республикасы бәяләүчеләр берлеге» КП ның 27.01.2025 ел, № 26 хатының уртача кыйммәте кулланылды

а) ялгыз яшәүче граждан өчен:

СЖ = 45 806 х 18 х 1 = 824508 сум

б) ике кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 45 806 х 18 х 2 = 1649016 сум

в) өч кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 45 806 х 54 = 2473524 сум

г) дүрт кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 45 806 х 72 = 3298032 сум

д) биш кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 45 806 х 90 = 4122540 сум

е) алты кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 45 806х 108 = 4947048 сум

ж) җиде кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 45 806 х 126 = 5771556 сум

2. Гаиләнең һәр әгъзасына туры килгән уртача айлык гомуми керемнең чик кыйммәте:

ПД =0,7 х СЖ х ПС/(1-(1 + ПС)$^{-КП}$)/(0,3 х РС), монда

СЖ - социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны бирү нормасы буенча торак урыны сатып алуның базар бәясенең исәп хисап күрсәткече;

ПС - айлык кредит буенча процент ставкасы (25 % еллык яки 25/100/12 аена, башлангыч взнос шарты белән 20%);

КП - кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (айлар саны) (кредит бирү вакыты 20 ел яки 240 ай «Татарстан Республикасы Ипотека агентлыгы» АҖ мәгълүматлары буенча;

РС -гаилә әгъзалары саны;

0,7-кредит суммасы һәм фатир бәясе нисбәте;

0,3 -кредит буенча түләүнең гаилә айлык кереме белән нисбәте,

а) ялгыз яшәүче граждан өчен:

$$ПД = 0,7 x 824508 x 0,02/ (1- (1 + 0,02)^{-240}) /(0,3 x 1) = 38811 сум$$

б) ике кешедән торган гаиләгә:

$$ПД = 0,7 x 1649016 x 0,02/ (1-(1 + 0,02)^{-240}) /(0,3 x 2)= 38811 сум$$

в) өч һәм аннан да күбрәк кешедән торган гаиләгә;

$$ПД = 0,7 x 12473524 x 0,02/ (1-(1 + 0,02)^{-240}) /(0,3 x 3)= 38811 сум$$